**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2019 № 1028

2020 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы «Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, һәм фәнни-техник һәм культурология юнәлешендәге дәүләт мәгариф учреждениеләре һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы карары һәм Кама Тамагы муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы Муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының белем бирүне тормышка ашыруның норматив чыгымнарының кушымтасын;

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының белем бирүне тормышка ашыруның норматив чыгымнарының 0,5 күләмендәге төзәтмә коэффициентын;

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль район Башкарма комитетының 19.11.2019 елның 1028 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик,социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларының һәм күппрофильле мәгариф оешмаларының балаларга өстәмә белем бирү буенча программаларын тормышка ашыру буенча

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Урнашкан урыны | Норматив чыгымнар (1 укучыга ,бер елга /сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Укытуның беренче елы | Укытуның икенче елы | Укытуның өченче елы һәм аннан соңгы еллар |
| Эстетик сәнгать юнәлеше | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристик-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |